ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№_326_____ от «__28__»___04_____2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ”Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында” 2018 ел, 30 март, 195 нче санлы карарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Татарстан Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Билгеләргә:

Хезмәт хакын түләү буенча бердәм тариф челтәренә карамый торган Мамадыш муниципаль аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләренең, белгечләр һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфа кеременнән, эшләнгән еллар өчен вазыйфа кеременә айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык вазыйфа кеременә өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча бүләкләүдән, һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә тоган түләүдән, матди ярдәм күрсәтүдән, һәм шулай ук закон нигезенә туры килә торган башка түләүләрдән тора. Белгечләр һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләү, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве өчен һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкару керүне;

аерым оешма эшчеләренең хезмәт хакы айлык тариф бәясеннән, компенсация түләүләреннән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык тариф бәясенә өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча бүләкләүдән, һәр ел саен алына торган түләүле ялларга бирелә торган матди ярдәмнән, машина йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмәдән, һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләүдән, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве

һәм үзенең төп эше белән берләттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкарганга түләүдән, шулай ук закон нигезенә туры килә торган башка түләүләрдән торуны;
аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме вазыйфаи окладның кыскача күләме исәпләнә муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе, сәркатибе Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре тарала, ул 11 163,0 сум тәшкил итә;
аерым учреждениеләр эшчеләренең айлык тариф ставкалары һәм компенсация түләүләре күләме Мамадыш бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган акчалар хисабынан;

2. Расларга:

бюджет өлкәсенең аерым оешмалары структур бүлекчәләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең бердәм таратылмый торган вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләүдә кулланыла торган бермәбер коэффициентлары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча тариф челтәре 1 № лы кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләүдә кулланыла торган бермәбер коэффициенты 2 № лы кушымта нигезендә.

3. Аерым оешмалар җитәкчеләренә, белгечләргә һәм хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процентта |
|---|---|
| 1-5ел | 5 |
| 5-10 ел | 7 |
| 10-15 ел | 10 |
| 15 елдан югары | 15 |

2) эшне катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

3) хезмәт окладының 2 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнә алмый);

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр җитәкчегә, белгечкә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләнгән вакытка пропорциональ рәвештә

исәпләнә һәм ул декабрьдә, эштән азат ителгән очракта – соңгы көннән дә соңга калмыйча, түләнә.

Еллык түләүле ял вакытында бер тапкыр бирелә торган түләү җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә беренче эш елында эшләгән вакыт дәверенә карап түләнә. Эшләгән вакыт дәвере эшкә кергән көннән алып шул елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

6) Матди ярдәм, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләү, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкарганга түләү вазыйфа кеременең 50 % кадәр билгеләргә, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында.

5. Хезмәткәрләргә Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләрне гамәлгә ашырырга.

6.Аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда акча суммасыннан тыш, түбәндәгеләрне билгеләргә:түләү өчен җибәрелә торган вазыйфаи окладлар түләү өчен түбәндәге чаралар карала (бер елга 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә-вазыйфаи окладларның җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазифаи окладка айлык өстәмә-вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - вазыйфаи окладларның бер проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү – вазыйфаи окладларның ике проценты күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск һәм вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;

7. Аерым оешмалар эшчеләренә хезмәт өчен түләү фондын тариф ставкаларын түләү өчен (компенсация түләүләрен исәпкә алып) җибәрелә торган акчалар суммасыннан тыш формалаштырганда түләү өчен түбәндәге акчалар карала (бер елга исәпләгәндә):

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләү-бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) класслык, нормалаштырылмаган эш көне өчен машина йөртүчеләргә айлык өстәмә түләү – тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр – өч айлык тариф ставкалары күләмендә;

4) еллык түләүле ял биргәндә матди ярдәм-айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

8. Билгеләргә:

- аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме арту ягына бер сумга кадәр җитәргә тиеш;

- аерым оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладларын арттыру Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының шундый ук

вазыйфадагы муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру өчен каралган күләмнәрдә һәм срокта башкарыла;

- аерым оешма хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын күтәрү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә хезмәткәрләренең шундый ук категория вазыйфаи окладларын күтәрү өчен каралган күләмнәрдә һәм срокларда башкарыла;

әлеге карар кабул ителгәннән соң, аерым оешмалар хезмәткәрләренә түләүнең башка шартлары кулланылмый.

9. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә.

10. Аерым оешмалар җитәкчеләренә:

хезмәткәрләр вазыйфаларының атамаларын 1 нче санлы кушымта нигезендә эшләргә;

моңа кадәр аерым оешмалар хезмәткәрләренең өстәмә түләү һәм башка түләүләр билгеләү турында булган актларны әлеге карар белән тәңгәлләштерергә.

11. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының түбәндәге карарларын гамәлдән чыккан дип танырга:

"2012 елның 1 октябреннән Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 02.10.2012 ел, 2068 нче санлы карары;

"2013 елның 1 октябреннән Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 30.09.2013 ел, 694 нче санлы карары;

« Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү турында" 01.11.2013ел, 1532 нче санлы карары;

"2017 елның 1 октябреннән Мамадыш муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 21.09.2017 ел, 1114 нче санлы карары;

12.Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов